СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

17 октябрь, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 117 (8129) | Бәясе билгеләнгәнчә

## АНОНС

### Редакциянең «түгәрәк өстәл»е артында эшлекле әңгәмә



Сишәмбе, 14 октябрь көнне редакция коллективының чакыруы буенча быелгы зур уңышка турыдан - туры кагылышы булган бер төркем иптәшләр «түгәрәк өстәл» артына әңгәмәгә җыелдылар. Авыл хуҗалыгында реформалаштыру, аның киләчәге проблемалары, быелгы уңышның алшартлары, аның крестьян фикерләвенә тәэсире һәм башкалар турындагы эчкерсез эшлекле әңгәмә барышы турында сез газетабызның киләсе санында таныша аласыз.

## ИГЪТИБАР:

**18 октябрь көнне Норлат аэропорты янындагы сабантуй мәйданы Норлатлыларны һәм районның авыл эшчәннәрен «Уңыш - 97» бәйрәменә җыя.**

### *Кадерле якташлар!*

Бу көнне сезне чын ял, күңел ачу чараларын эченә алган бәйрәм көтә. Анда нәкъ язгы сабантуйдагы төсле атлар парады, ат чабышлары, һәртөрле спорт ярышлары (моңарчы булганнарына биеклеккә сикерү, 100 метрга йөгерү дә кертелә).

Спорт - күңел ачу уеннары (капчык киеп, йомырка кабып, көянтә белән йөгерү, капчык сугышы, багана башына менү һ.б.) булачак.

Ат чабышларын быел зур мәртәбәле итеп «Татнефть» АҖсе оештырачак, көчләрен сынарга нефть районнарыннан да иң җитез чаптарлар килергә әзерләнә. Нефтьчеләр шулай ук автокросс һәм мотокросс үткәреп бәйрәмдәгеләрне шаккатырырга җыеналар. Иң дулкынландыргычы - милли көрәш тә тамашачыларны күп җыяр дип уйлыйбыз. Бәйрәм үтәсе мәйдан сезне күркәм бизәлеше, мул сәүдә рәтләре (авыл хуҗалыгы ассоциацияләре, оешма, предприятиеләр дә сату итәчәк), бай концерт программасы белән дә таң калдырырга җыена. Бу көнне республика татар эстрадасы йолдызлары, җирле талантларыбыз район авыл хуҗалыгы алдынгыларын хөрмәтләп чыгыш ясаячак.

Әлбәттә, кыр батырлары, урак алдынгылары бәйрәмнең иң кадерле, хөрмәтле кунаклары булачаклар. Сез бу көнне иң алдынгы хуҗалыклар, иң фидакарь игенчеләр исемен ишетерсез, аларны олылауның шаһиты булырсыз.

Нәни норлатлылар карамагында бу көнне «Балалар шәһәрчеге» эшләячәк.

**Бәйрәмгә әзерләнегез, җилдәй җитез аргамакларыгызны ярышка иярләгез, якташлары өчен сөенеп тамаша кылырга кунаклар чакырыгыз!**

**Кунакчыл Норлат җиренә бәйрәм килә, муллык бәйрәме, уңыш бәйрәме.**

## *Хөрмәтле дуслар!*

**1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу бара. Язылу бәясе ярты елга 26.400, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.**

**Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.**



Ел саен «Татнефть»нең һәр идарәсендә төрле һөнәрләр буенча профессиональ осталыкка конкурслар үткәрелеп тора. Руль артындагы һөнәр ияләре нефтьчеләр өчен шуларның иң мөһимнәреннән берседер, мөгаен. «Норлатнефть» НГДУсының технологик транспорт идарәсендә аларның төрле машина маркалары буенча конкурслары оештырылды. Шуларның берсе ЗИЛ - 130лар арасында Валерий Малейкин җиңүче исемен яулады. Валерий УТТда 6 ел эшли һәм шул вакыт эчендә үзен конкурстан тыш та оста шофер итеп таныта алды. Үз машинасы белән ул җәен урып - җыю кебек җаваплы чорда да катнашты.

**Рәсемдә: УТТ шоферы В.П.Малейкин.**

**Н.КВАШИНА фотосы.**

● *Кискен сигнал*

## Елаурда солы ...тишелә

МСОның «Строитель» агроцехыннан сабан культуралары орлыкларының сыйфатын тикшертү өчен дәүләт орлык инспекциясенә китермәүләренә аптыраган идек. Баксаң, моның үзенә күрә «сере» бар икән. Хуҗалыкта орлыклык материалның һәм фуражга салынган ашлыкның нинди шартларда тотылуын барып үз күзләребез белән күргәч, инандык монысына. Елаурдагы ашлык складларының берсендә генә дә тулы тәртип бар дияргә тел әйләнми. Складларның искеләренең түбәсендә тишек -тошыклар гына булса, быел салына башлаганының исә түбәсе ябып бетерелми калган, шуңа күрә аның бер башындагы орлыклык солыга яңгыр үтә, ә икенче башындагы фуражга дигән солы... тулысы белән ачык һава астында дияргә була. Шуңа күрә дә ул аслы - өсле үреп ята. Барлы - юклы борчак орлыгына да сан юк хуҗалыкта. Ашлык складларында чит әйберләр саклануны, шул исәптән фураж янәшәсендә агуланган кукуруз орлыгы да тотылуны шулай ук нормаль хәл диеп булмый. Чәчүлек бодай һәм солы орлыклары саклана торган складлары ышанычлы булган Петровскийда да вика һәм солы катнашмасы ындыр табагына кырдан кайтарып бушатылган кее. Анысын эшкәртергә тотынган булганнар булуын, әмма тәмамларга өлгермәгәннәр һәм ул кызып үреп ята бирә. Ә мәйданчык кырыйларында чәчелгәне инде бөтенләй эштән чыккан.

Ашлыкка әнә шундый караш монда. Ә инде чәчүлек материалны калибрлауга тотынырга уйлаган кеше дә юк әле. Хәер, ашлык инде складта ук тишелеп ятканда, нигә аларның тишелешен, башкача сыйфатын тикшертеп азапланырга ди?

**Ф.МИНГАЛИМОВ,**
**район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе агрономы.**
**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

## Сессия булды

15 нче октябрь көнне район хакимияте конференц залында халык депутатлары Октябрь район Советының чираттагы XII нче сессиясе булды.

Аның эше күңелле нотадан башланды. Халык депутатлары Октябрь район Советы рәисе Ф.С.Сибагатуллин 70 еллык юбилее һәм истәлекле туган көне уңаеннан сугыш һәм хезмәт ветераннары район Советы рәисе И.У.Гыйләҗевка һәм халык суды рәисе Г.Н.Гришовага хакимият һәм район Советының Мактау грамоталарын тапшырды. «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исеме тапшырылу турында Мактау грамоталары һәм күкрәк билгеләре Мичурин исемендәге КХА рәисе И.Н.Мөхәммәтов, «Алга» КХАсы рәисе Р.Р.Хәмзинга, «Татарстан Республикасының атказанган экономисты» исемен бирү турындагы грамота Синдряков исемендәге КХАның баш бухгалтеры Н.И. Храмовага тапшырыла. Аннан соң Ф.С.Сибагатуллин Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиевның район агропромышленность комплексы хезмәткәрләренә рекордлы икмәк уңышы алуда куйган фидакарь һәм җитештерүчән хезмәтләре өчен рәхмәт хатын укыды.

XII нче сессиянең район Советы президиумы тарафыннан тәкъдим ителгән көн тәртибе үзгәрешсез калды. Октябрь район Советына 13 нче Дальный сайлау округы буенча сайлау нәтиҗәләре турында район сайлау комиссиясе рәисе Н.Х.Абдуллин информация ясады. Халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе урынбасары итеп депутатлар бертавыштан хакимият башлыгының советлар белән эшләү буенча киңәшчесе А.Н.Ельченковны (13 нче Дальный сайлау округы) сайладылар. Аннан соң совет аграр мәсьәләләр буенча даими комиссия составына үзгәрешләр кертте. Е.К.Савинов (15 нче Биляр Озеро сайлау округы), комиссия әгъзасы, ә Р.Р.Хәмзин (12 нче Аксумла - Якушкино сайлау округы) - әлеге комиссиянең рәисе итеп сайландылар. Көн тәртибе буенча сессия социаль мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе А.Л.Клементьев (14 нче Чаллы сайлау округы) информациясен тыңлады.

1997 нче елның 9 аенда район бюджеты үтәлеше турында депутатларны район хакимияте башлыгының урынбасары - финанс бүлеге мөдире Р.Г.Билалов таныштырды. Халык депутатлары Советы кайбер өстәмәләр һәм үзгәрешләр белән районда 1997 - 1999 елларда җинаятьчелеккә каршы көрәшнең комплекслы программасын да раслады, әлеге программаны район эчке эшләр бүлеге начальнигы В.В.Иванов бәян итте. Бу мәсьәлә буенча фикер алышуларда район прокуроры А.П. Евграфов чыгыш ясады.

Коопзаготпром директоры Җ.З.Әхмәдиевның районда авыл хуҗалыгы продукцияләрен сатып алуның барышы турындагы информациясе катнашучыларда аерата кызыксыну уятты. Әлеге мәсьәлә буенча фикер алышуларда М.С.Моратов (24 нче Бикүле сайлау округы) һәм Елаур җирле үзидарә Советы рәисе П.П.Иванов иптәшләр чыгыш ясадылар.

Барлык каралган мәсьәләләр буенча халык депутатларының район Советы тиешле карар кабул итте. Сессия эшендә җирле үзидарә Советлары рәисләре, крестьян - фермер хуҗалыклары ассоциацияләре, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре катнаштылар.

## ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

Сессиядән соң узган киңәшмәдә сүз авыл эшчәннәре каршында бүген торган кичектергесез мәсьәләләр турында барды. Җирләрне туңга сөрү, кукурузны бөртеккә суктыру, чөгендер казу һәм үстерелгән уңышны заводка озату - болар һәммәсе КХА җитәкчеләренең кичектергесез һәм даими игътибарын таләп итәләр. «Якты көннең һәр сәгатен җитештерүчән файдаланырга, тракторларның төнге эшен оештырырга, кырда эшләүчеләр өчен барлык шартларны тудырырга»,- дип ассызыклады Ф.С.Сибагатуллин. Терлекчелектә аерым хуҗалыкларда эшләрнең торышына канәгатьсезлек белдереп, хакимият башлыгы бу көннәрдә һәр сыердан сөт савуны 3,2 килограммга гына калдырган «Үрнәк», Нефтебаза ярдәмче хуҗалыгы (3,2 килограмм) һәм «Комбайн» (3,8) ассоциацияләрендә аерата түбән савым булуын ассызыклады. Сөйләшү авылда җитештерү мөнәсәбәтләрен реформалаштыру нәтиҗәләрен анализлау белән төгәлләнде.

Киңәшмә эше тулаем алганда бик кискен, конкрет характерда узды.

# Урак бетте, эш дәвам итә



Тигез итеп сөрелгән кап - кара басуларда горур булып утырып торучы салам өемнәрен күрәсезме МТЗ - 80 тракторында кибән куйгычта эшләүче механизатор Рамил Әхмәтшин, кибән куючылар Габбас ага Әһлиуллин һәм Рөстәм Баһмановның тырыш хезмәте нәтиҗәсендә мал азыгы үзвакытында җыелып, җиренә җиткереп өеп куелды.

Әмма «Таң» КХАсы члennарына эш бетмәде. Рамил хәзер тракторы белән хуҗалыкта йөкләр ташу эшенә күчте, Рөстәм фермага килде, ияләшкән хезмәте - маллар янында эшли башлады. Иң өлкәннәре Г.Әһлиуллин да өйдә утырырга җыенмый - хуҗалык наряды нигезендә һәр көнне хезмәттә күрәсең аны.



**Рәсемнәрдә: «Таң» КХАсы хезмәтчелләре Р.Әхмәтшин, Г.Әһлиуллин, Р.Баһманов.**

## УКЫТУЧЫЛАР ЯЗШЫ ЯШӘЯЧӘК КИЛӘЧӘКТӘ

РФ хөкүмәтенең вице-премьеры Олег Сысуев әйткәнчә, киләсе ел азагына, ягъни «Русия икътисадый тотрыклылык һәм үсеш тоюга»,хөкүмәт укытучыларнның хезмәт хакын арттырачак.

Ә бүгенге көндә хөкүмәтнең укытучыларга 9 триллион сум бурычы бар.Хәер,Гомуми һәм һөнәри белем бирү министрлыгының матбугат үзәге 1988 елның 1 гыйнварена укытучылар акчаларын тиенен кадәр алып бетерәчәкләр дип ышандыра.

*Түбән Норлаттан Самара өлкәсенең Кошки районы Дала Мамыгына кадәрге юлны гадәттә булмаганча итеп төзиләр. Халык биредә запас аэродром була икән дип тә сөйли. Бу сүз дөреслеккә туры киләме?*

*Х.ХАТЫЙПОВ.*
*Норлат шәһәре*

## Гади, әмма гадәти булмаган юл

- Гадәти юл бу,- дип каршылады безне трассада участок начальникы Владимир Афонькин - «Тататводор» заказы буенча «Татдорстрой» автомобиль юллар төзү берләшмәсе (ОСАД) төзи аны.

Юл булса юл булсын. Югыйсә, Түбән Норлат белән Дала Мамыгы арасындагы бу ара күптән үги хәлдә иде инде. Шөкер, озакламый бу проблема хәл ителәчәк, һәм игътибарсыз калган бердәнбер «чик яны зонасы»да табадай тигез юллы булачак, димәк. Әмма юлның да нindие әле...

Газетага хат язучы Х.Хатыйпов күпмедер дәрәҗәдә хаклы: гадәти юл түгел ул. Без йөрергә күнеккән һәм техникалар бер - берсенә аздан гына «ышкылып» юл бирүче 6 - 7 метрлылардан күпкә үзгә бу ара. Иң элек киңлегенең 8 метр булуын әйтәсе килә. Ул экспериментал ь һәм III категорияле булачак. Юл ГОСТ таләпләренә туры килә: анын аскы һәм өске өлешләре барысы да юл төзелешендә кулланыла торган иң сыйфатлы материаллардан эшләнгән. Инерт материаллар, мәсәлән, Жигулевск карьерыннан кадәр кайтартылган. Комы елганыкы, әмма анысы да гадәти түгел, юылган, югары фильтрацияле. Өске өлешенә түшәлгән асфальт - бетон да югары сыйфатлы. Белгечләр раславынча, әлеге юлның гарантия срогы да 3 ел (!) булачак икән. Мондый гадәти булмаган юлни өчен бу арага гына салына соң?

## Урта Идел зонасында бердәнбер - безнең районда

Эш шунда ки, биредәге юлны без гадәттә күрергә күнеккән ысул белән түгел, махсус Америка комбайны, төгәлрәк итеп әйтсәк - профильләүче ДС - 99 - автогрейды ярдәмендә төзиләр. Һәм шунысын да искәртәсе килә, мондый югары җитештерүчән техника элеккеге Советлар илендә дә бармак белән генә санарлык икән. Шуның берсе Урта Идел зонасында бердәнбер булганы хәзер безнең районда эшли.

Газета укучыны мондый мобиль техниканың ничек итеп безнең районга килеп чыгуы да, гадәти булмаган эш принцибы да кызыксындырадыр инде, мөгаен. Әлеге комбайн тулаем ДС - 100 автогрейды комплектының бер берәмлеге. Америкада 1972 нче елда чыгарылган булган. Ульяновскида белән 2 аэродромга асфальт - бетон салганнар. Тольяттидагы әйләнү юлын төзегәндә дә әлеге техниканы кулланганнар. Автогрейд Казан аэропортында да эшләгән. Безгә исә ул шуннан кайтарылган.

Аңлашыла ки, профильләүче комбайнның эксплуатация срогы күптән узган. Әмма юл төзүчеләр билгеләгәнчә, Америка комбайны ОСАДның баш инженеры Александр Михайлович Уточкинның тырышлыгы бәрабәренә генә гомере озая. Двигатель «шакылдагач», аны эзләп Чимкентка кадәр җиткәннәр бит.

Тулаем алганда, ДС нигездә аэродромнар төзүдә кулланыла. «Табадай» тигез, корычтай нык юллар төзергә кирәк булганда әлеге техникадан да ышанычлырагы юк инде анын. Юлга гарантияне дә 8 елга бирә бит ул. Дөрес, юл төзелешендә дә бу комбайн бик отышлы. Кыл (струна) буенча эшли ул. Юлга нигез салганда шнеклар һәм бүлгечләр ярдәмендә комны да, вак таш та тиешле калынлыкта, киңлектә салына. Автогрейдта эшләүче 4 кеше исә эшне карап - күзәтеп, шуның 2 се кылларны күчереп, төзәтеп торалар. Гомумән, югары җитештерүчән эшли бу техника. Әмма...


- Җир полотносының 12 - 14 метрлы булуы таләп ителә. Шуңа да ДС - 99ны бары тик яңа юл төзегәндә генә кулланып була,- ди Владимир Иванович.

## ДС - 99 - ОСАДныкы

Газета укучы аңлагандыр инде, ДС - 99 - ОСАДныкы.

ОСАД (автомобиль юллары төзү берләшмәсе) үзе исә «Татдорстрой» ОООна карый. Норлатта бу оешма быелның май аенда районыбыз хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин үтенече буенча республика юл фонды әмере белән оешкан. ДРСУда «фатирда» торучы бу берләшмә безнең районда автомобиль юллары төзиячәк. Яңа оешма тиз арада аякка баскан. Бүгенге көндә биредә 60лап кеше эшли. Аларның байтагы нигездә юл төзүчеләр эш фронтына бәйле рәвештә тагын да үсәчәк әле берләшмә. Коллектив белгечләр белән дә җитәрлек дәрәҗәдә комплектланган. Матди база да ярыйсы. Төрле маркадагы бульдозерлар, скреперлар, төягечләр бар. ДС - 99 профильләүче агрегат үзе генә дә ни тора! ОСАД исә районда автомобиль юлларын тиз дә, сыйфатлы да салуны максат итә.

**Р.ГИНЯЕВА.**
**Рәсемдә: менә ул ДС - 99.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**



# Тормышымны мөстәкыйль төзермен

***Тәрәзә артында яңгырлы октябрь. Җәйге каникуллардан соң менә инде икенче ай студентлар институт һәм колледжларда белем үрләрен штурмлыйлар. Яшьләр читтә ата - аналар күзәтүеннән башка ничек яшиләр? Казан югары уку йортларының берсенең өлкән курсларында укучы Лилия безгә фамилиясен әйтмичә генә шулар турында сөйләргә булды.***

- Тулай торакта яшим. Бүлмәбез өч кешегә исәпләнгән. Әмма биредә без дус кызым белән икәү генә яшибез. Көнкүреш уңайлыклары? Безнең катта яларсыз 7дән 23 сәгатькәчә бер душ эшли. Безнең блокта 8 бүлмә, кухнябыз бер генә - бирегә без йозак куйдык, шунсыз кәстрүл яисә табасыз калырга мөмкин. Ашның плитәдән югалган очраклары да булды... Безнең тулай торакта кызлар да, егетләр дә, чит илдән килүчеләр дә, гаиләлеләр дә яши. Гаепне кемгә аударырга да белмисең. Хәер, урлашу очраклары аз булмый. Иптәш кызымның кулмәген урладылар - табылмады, аяк киемнәре, сөлгеләрне алып китәләр...

Икенче сменада укыйбыз, шуңа да институт ашханәсенә йөрмибез - ашны үзебез чиратлап хәзерлибез. Әниләргә рәхмәт, өйрәттеләр, ә хатын - кызга бу тормышта бик кирәк нәрсә. Барлык азык - төлекне өйдән алып киләбез. Минем дус кызым авылдан, ата - аналарының үз хуҗалыгы бар, калган чыгымнарны икебезгә тигез итеп бүләргә тырышабыз.

Безнең группада 19 кеше һәм шуларның 4се генә егетләр. Бер гаилә пары бар. Студентларның күпчелеге Казаннан, барысы да яхшы киенәләр. Без читтән килүчеләрнең алардан калышасы килми. Шуңа да бүген миңа үземә джинсы, модалы свитер һәм башкаларны алу өчен ата - анама кыенга туры килә. Стипендияне нигездә даими түлиләр - азык - төлек чеклары белән ул җәмгысе 110 - 120 мең сум тәшкил итә. Шуның 20 меңен тулай торак өчен алып калалар. Ай саен проездной билет алам, институтка трамвай яисә троллейбус белән йөрергә туры килә. Атнага бер тапкыр өйгә шалтыратам, айга бер тапкыр кайтып киләм. Прописькам вакытлыча, Казанныкы, шуңа да самолетка билетны 80 мең сумга алырга туры килә. Ә шәһәрара автобуста льготалы тарифлар бар. Менә инде ике ел кичләрен мин Зур концерт залында карауч ы булып эшлим. Бу эшне миңа дус кызым тапты. Анын белән бергә атнага ике - өч тапкыр махсус формалар киеп без махсус билгеләнгән урында залда дежур торабыз - тәртип саклыйбыз, тамашачылар кәнәфиләр артына сагыз тышларын яисә сыра банкаларын ыргытмасыннар, зал буйлап йөрмәсеннәр дип күзәтәбез. Эшебез өчен безгә ай саен 300 мең сум түлиләр. Шимбә һәм якшәмбе көннәребез буш була. Без атнага 5 көн генә укыйбыз. Күп укыйм - Татарстан Республикасы милли китапханәсенә язылдым.

Бер елдан мин институтны тәмамлыйм. Казанда калырга яисә Яр Чаллы шәһәренә урнашырга тырышачакмын. - Норлатта перспектива юк. Зур шәһәрдә яшисем һәм тормышымны шәхси үлчәүләрем һәм интересларым буенча корасым килә.

**Т.АЛЕКСЕЕВА**
**язып алды.**

*Кичәге почтадан*

# Бәйрәм күңелле үтте

Һәр елны октябрь аеның беренче якшәмбесендә укытучылар көне билгеләп үтелә. Бу традицион бәйрәмне безнең Түбән Норлат урта мәктәбе дә читтә калдырмады. Коллективта эшләп, лаеклы ялга чыккан абый - апаларыбыз да бәйрәмгә чакырылган иде. Алар безнең яшь, дус һәм тату коллективны күреп яшьлекләрен сагынып искә төшерделәр.

Тантаналы бәйрәм кичәсен мәктәпнең 5 нче сыйныф укучылары концерт монтажы белән ачып җибәрделәр. Мәктәбебезнең оештыручылары В.С. Хәлитов һәм М.С.Тимербулатоваларның зур тырышлыгы ярдәмендә бик матур җырлы - биюле концерт программасы күңелләрне йомшартып җибәрде. Изге җаннарыбыз - кунаклар кулына матур чәчәк букетлары тапшырылгач, бәйрәм мул табын артында дәвам итте.

Бәйрәмгә безнең укытучылар коллективына тирән ихтирам йөзе күрсәтеп, җирле үзидарә Советы рәисе С.Ильмухин да килгән иде. Ул үзенең җылы, матур котлау сүзләре белән коллективыбызга мәңге яшәргә көч бирде.

Районнан килгән мәгариф бүлеге вәкиле Н.Бикулов та котлау сүзләрен ирештерде. Ул мәктәптә элек эшләп, лаеклы ялга китүче М.Х.Хисмәтуллинга һәм Ш.К.Әхмәдиевка котлау открыткалары һәм лаеклы хезмәтләре өчен бирелгән Мактау кәгазьләрен тапшырды.

Бәйрәм агымында сүзне Киекле мәктәбе укытучысы Роза апа Мәслахова алды. Түбән Норлат авылында туып үскән талант иясе, иҗатчы, шагыйрә авылыбызның горурлыгы булып тора. Ул авылыбызга багышлап иҗат иткән әсәрләрен укыды, үзе язган шигырьләренә көй чыгарып, аны безгә җырлап та күрсәтте. Бәйрәмнең соңгы өлеше - җырлар, биюләр, изге теләкләр белән тәмамланды.

**Ф.ӘХМӘДИЕВА.**



**Шиңеп барган көзгә гөлләр кебек**
**Ятим, кайчак чирле Өлкәнлек.**
**Бер җылы сүз эзләп чыктым әле**
**Аны бераз ямьле итәрлек.**

Өлкәннәр ункөнлеге үтте

## БҮЛӘК ИТЕП АРАЛАШУ КУАНЫЧЫН

Бу айның беренче ункөнлеге безнең ветераннарга шатлыклы очрашулар һәм вакыйгаларны күпләп алып килде. Район мәдәният йортыннан агитбригада килгәндә Чулпан картлар йортында яшәүчеләрнең кәефе бермә - бер яхшырды: гадәттә бирегә кунаклар сирәк килә, ә җилкенеп бию һәм дәртле җыр йөрәккә май булып ята. Бу - 1 октябрь көнне концерт программасы белән биредә «Сялгусь» ансамбле, О.Җиһаншина бию коллективы, С.Миннеханов, Норлат шикәр заводы сәхнәсе ветераннары чыгыш ясадылар, икенче көнне өлкәннәр район үзәгендәге бер эшмәкәр тарафыннан әзерләнгән кондитер наборлары алдылар. Озакламый алар янына Норлатның 3 нче мәктәбе укучылары да кунакка киләчәк.

6 октябрьдә Чулпан урта мәктәбе дә үзенең кунакларын каршы алды. Ветераннар белән очрашуда район хакимияте каршындагы халыкны социаль яклау идарәсе начальнигы Л.Н.Дилмөхәммәтова катнашты. Ул районда социаль - икътисади үсеш программасының үтәлеше белән таныштырды. Укучылар кунакларга әдәби - музыкаль монтаж күрсәттеләр, ә соңрак чәй табынында сыйландылар.

7 октябрьдә «Ветеран» клубы әгъзалары өлкәннәр көненә багышланган чираттагы җыелышларына җыйналдылар. Һәрвакыттагыча очрашу җылы һәм шатлыклы үтте: хатын - кызлар өстәлне көзге байлыклар белән тутырдылар, шәхси рецептлары белән алмаштылар, яраткан җырларын тыңладылар һәм җырладылар. Алар таралышканда караңгы кич иде инде, ә күңелләрдә аралашуны дәвам итү теләге әле зур иде.

## Ә безне оныттылар

...Без өлкәннәр көне һәм декадасыннан бөтенләй читтә калдык. Дөрес, пенсиягә биредән чыкмадык. Беребез пенсиягә колхозда эшләп чыкты, аңа 94 яшь, үзем Иркутск өлкәсендә 23 ел эшләп, бирегә кайттым, аңа кадәр 10 ел Чулпан шифаханәсендә эшләгән идем, алар да мине искә алмадылар. 5 ел эчендә безне бары бер тапкыр, Заречный авыл Советы рәисе булып М.П.Стажарова эшләгәндә котладылар. Аңа рәхмәт укып, бүген онытылуыбызга күңелебез тула.

**Н.Галанина, В.Белова, А.Белова, А.Савинова.**
**Заречный поселогы**

*Игътибар: яңалык!*

# Пенсияне яңадан исәпләү тәртибе

Гражданнарны пенсия белән тәэмин итү проблемаларын хәл итү өчен Россия Федерациясе хөкүмәте пенсия белән тәэмин итү системасында реформа ясау концепциясен хуплады. Беренче адымнар ясалды инде - 1996 елның 1 апрелендә «Дәүләт пенсия страхованиесе системасында индивидуаль (шәхси) учет турында» Федераль закон кабул ителде. Бу законда барлык эшләүчеләрнең страхование (иминият) взнослары түләве, ягъни пенсияләрне үзләре «эшләп алу»ы күздә тотыла. Безнең республикада иминият взносларын индивидуаль исәпкә алу этаплап, 1998 елның 1 февраленнән башланачак. Хәзерге вакытта Пенсия фонды бүлекчәсе шушы эшне оештыру белән мәшгуль. Әмма индивидуаль учет турындагы Закон яшьләргә дә, әле пенсия яшенә җитәргә шактый озак булган кешеләргә дә кагыла. Ничәмә - ничә ел буена бер пенсиягә яшәүче гражданнар яхшы белә моны. 1997 елның 21 июлендә кабул ителгән «Дәүләт пенсияләрен исәпләү һәм арттыру тәртибе турында»гы закон шушы пенсионерларга кагыла да инде. Ул этаплап гамәлгә ашырылачак. Беренче этабы, әйткәнемчә, 1998 елның 1 февраленнән башланачак. Киләсе этаплар аерым федераль законнар белән билгеләнер.

Бу законда нинди яңалык бар соң? 1997 елның 21 февралендә кабул ителгән «Дәүләт пенсияләрен исәпләү һәм арттыру тәртибе турында»гы законның 1 нче статьясында әйтелгәнчә, дәүләт пенсияләре, Россиядә эш хакы арта баруга бәйле рәвештә, яңа индивидуаль коэффициентта, хезмәт стажы да, уртача эш хакы да исәпкә алына. Мәсәлән, пенсионерның хезмәт стажы 42 ел ди. Аңа пенсия 1982 елгы эш хакыннан чыгып, 1983 елның гыйнварында 210 сум итеп билгеләнгән ди. Әйтик, 1982 елда илдә (Россиядә) уртача эш хакы 187 сум иде ди. Ә 1998 елның 1 февраленә уртача эш хакын, мәсәлән, 900 мең сум дип алыйк, шулардан чыгып кабат исәпләү болай үткәрелә:

1. Пенсионерның 1982 елда фактик эш хакы булган 210 сумны 187гә бүләсең - 1,1 килеп чыга, әмма 1998 елның 1 февраленнән бу нисбәт 0,7дән артмаска тиеш.

2. 42 еллык хезмәт стажы процентларда 72 була (55 проценты 25 ел эшләгән өчен плюс кирәкле стаждан тыш эшләгән еллар өчен 17 процент). Димәк, 0,72 процентны 0,7гә тапкырлыйбыз һәм пенсионерның индивидуаль коэфициентын китереп чыгарабыз - 0,50 яки 50 процент.

3. Әгәр ил буенча уртача эш хакы 900 мең сум булса, ул чагында 1998 елның 1 февраленнән пенсия 450 мең сум (деноминацияне искә алып 450 сум) күләмендә билгеләнә.

Пенсияне индивидуаль коэфициентны исәпкә алып билгеләгәндә яки кабат исәпләгәндә гомуми эш стажына бары тик хезмәт эшчәнлеге һәм армиядә хезмәт итү генә һәм шуңа тиңләштерелгән, ягъни Законда «а», «е», «ж» дип күрсәтелгән эшчәнлек кенә керә. Болар - эш барышында башланган вакытлыча хезмәткә яраксыз булу вакыты, иректән мәхрүм итү урыннарында эшне яңадан караганда билгеләнгән сроктан тыш вакыт, эшсезлек буенча пособие алу вакыты.

Башка төр эшчәнлек, мәсәлән, уку чоры, эшләмәүче ананың 3 яшькә кадәрге баланы карап үстергән еллары, камалыштагы Ленинградта яшәүче, фашист лагерьларында тоткын булып яту, офицер хатыннарының ерак гарнизоннарда яки чит илләрдә яшәве, I группа инвалидны яки өлкән кешеләрне карау һ.б. вакытлар пенсионерның индивидуаль коэффициентын билгеләгәндә исәпкә алынмыйлар. Эш стажын икеләтә, өчләтә күләмдә льготалы исәпләү дә күздә тотылмый.

Менә бер мисал. Пенсионер хәзерге вакытта, компенсациясе белән бергә, 220 мең сум ала ди. 1987 елда аның уртача хезмәт хакы 130 сум булган булсын. Гомуми эш стажы 45 ел (39 ел эшләгән плюс 3 ел хәрәкәттәге армиядә хезмәт иткән - икеләтә күләмдә алсак, армия стажы 6 ел). Әйтик, 1987 елда илдә уртача эш хакы 216 сум, ә 1998 елның 1 февраленә 900 мең сум булган ди. Карар: пенсияне кабат исәпләү өчен армия хезмәте гомуми стажга календарь вакыт сыйфатында кертелә - 3 ел. Димәк, бөтен стажы 42 ел. Пенсионер эш хакының илдәге уртача хезмәт хакына нисбәте 0,6 (130ны 216га бүл). Индивидуаль коэффициент 0,43 яки 43 процент (42 еллык стаж өчен 0,72 процент x 0,6).

1998 елның 1 февраленнән пенсия күләме, әгәр илдә уртача эш хакы 900 мең сум булса, әлеге пенсионерныкы 387 мең сум була.

Әгәр пенсионерга пенсияне индивидуаль коэффициенты нигезендә исәпләү файдалы булмаса, ягъни компенсация белән бергә ала торган пенсиясе югарырак булса, аңа пенсия элеккечә түләнәчәк, индивидуаль коэффициент белән яңадан исәпләү үткәрелмәячәк.

Хәзерге вакытта бүлекләрдә белгечләр пенсия эшләрен яңадан исәпләүгә әзерлиләр: стажны исәплиләр һ.б. Шунлыктан, әгәр пенсионерның кулында эш урынында теркәлмәгән хезмәт стажы турында документлары булса, яки пенсионер пенсиягә чыкканнан соң да эшләсә, хезмәт стажына төгәллекләр кертү өчен, бу хакта мәгълүматларны социаль - тәэминат бүлегенә илтеп тапшырырга кирәк.

Соңгы этапта, Россия Федерациясе хөкүмәте Россиядә 1997 елгы уртача эш хакының күләмен раслагач, социаль - тәэминат бүлекләре 1998 елның 1 февраленнән пенсияләрне яңадан исәпләүгә керешәчәкләр.

**Д.НӘФЫЙКОВА,**
**Татарстан Республикасы Социаль - тәэминат министрлыгының пенсия бүлеге башлыгы.**
**(«Ватаным Татарстан»).**

## ЕЛЛАР, ЭШ ХАКЫ ҺӘМ ПЕНСИЯ

**Пенсионерларның редакциягә җибәргән күпсанлы үтенеч - мөрәҗәгатьләрен искә алып, без бүген 1960 - 1996 нчы еллар өчен эшче һәм хезмәткәрләрнең ил буенча уртача эш хакы (сумнарда) таблицасын тәкъдим итәбез. Биредә китерелгән суммалар сезгә, хәзер лаеклы ялда булган пенсионерлар һәм киләчәктә пенсиягә чыгарга җыенучыларга, хезмәт эшчәнлегенең «иң яхшы» чорын билгеләргә ярдәм итәр. Ул чакта сезнең һәм ил буенча уртача эш хакының уңай тәңгәл килүе сезгә зуррак пенсия исәпләргә булышыр.**

| | |
|---|---|
| 1960 - 80,6* | 1979 - 163,3 |
| 1961 - 83,9 | 1980 - 168,9 |
| 1962 - 86,7 | 1981 - 172,5 |
| 1963 - 88,2 | 1982 - 177,3 |
| 1964 - 90,8 | 1983 - 180,5 |
| 1965 - 96,5 | 1984 - 184,8 |
| 1966 - 100,2 | 1985 - 190,1 |
| 1967 - 104,7 | 1986 - 195,6 |
| 1968 - 112,7 | 1987 - 202,9 |
| 1969 - 116,9 | 1988 - 219,8 |
| 1970 - 122 | 1989 - 240,4 |
| 1971 - 125,9 | 1990 - 270 |
| 1972 - 130,2 | 1991 - 548** |
| 1973 - 134,9 | 1992 - 5995** |
| 1974 - 141,1 | 1993 - 58663** |
| 1975 - 145,8 | 1994 - 220351** |
| 1976 - 151,4 | 1995 - 472392** |
| 1977 - 155,2 | 1996 - 805924*** |
| 1978 - 159,9 | |

## Инвалидларга яңа өстенлекләр

***«Күптән түгел Татарстанда инвалидлар турында тагын бер өстенлек (льгота) турында карар чыккан дип ишеттек. Шул дөресме һәм ул III группа инвалидларга кагыламы?»***

**Бу сорауга Татарстан Социаль - тәэминат министрлыгының бүлек мөдире РӘИСӘ РӘШИТ кызы ВӘЛИЕВА җавап бирә.**

- Әйе, республика Министрлар Кабинеты агымдагы елның 9 июлендә шундый карар кабул итте (Карар номеры - 544). Аның нигезендә, өлкән яшьтәге һәр группага караган инвалидлар да телефон һәм радионокта белән файдаланган өчен тиешле сумманың 50 процентын гына түлиләр.

Тик моның өчен телефон станциясенә барып йөрүнең хаҗәте юк. Бары ВТЭКтан бирелгән инвалидлык турындагы белешмәне алып, районның социаль яклау бүлегенә генә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Анда исемлек төзеп аны телефон станциясенә бирәчәкләр. Ә инвалидлар сентябрьдән телефон белән файдаланган өчен 20 мең урынына 10 мең сум гына түли башлыйлар.

Ә радионоктага кагылган өстенлек торак - коммуналь идарәсе аша башкарыла. Шул ук ВТЭК белешмәсен торак - коммуналь идарәсенә барып күрсәтергә дә, аның хезмәткәрләре лицевой счетка билге ясагач, шулай ук түләнәсе 2500 сум урынына 1250 сум гына түләргә кирәк.

**(«Юлдаш» газетасыннан).**

# МӘГЪЛҮМАТ. МӘГЪЛҮМАТ

## Чәчәкләрне ничек сакларга?

***Чәчәкләрнең әле дә күп вакыты. Аларны ничек сакларга?***

**С.ВӘЛИЕВА.**

Вазадагы чәчәкләрнең гомерен озайтыйк дисәң, аларны кайчан өзәргә кирәк икәнен дә белергә тиешбез. Лаләләрне (тюльпан), мәсәлән, чәчәк бөресенә төс кергәч, ачылганчы ук, ә нәркисне (нарцисс) «муены сузылгач», ачыла башлауга өзәләр. Чалма чәчәкне (пион) һәм гөлчәчәкне (роза) ярым ачылгач кисәләр. Кәнәфер һәм кыңгырау чәчәкләрен дә яртылаш ачылгач, гладиолусны бер - ике чәчәге ачылуга кисәргә мөмкин. Бер еллык кашкарыйны (астра) һәм хризантеманы чәчәкләре ачылгач кына өзәргә кирәк. Чәчәк сабагын үткен пычак белән, кыеклап кисү әйбәтрәк. Нәркис, лалә, канәфер, хризантема, кашкарыйны сындырып кына алырга мөмкин. Чәчәкләрне иртән иртүк яисә кичен өзәләр.

Яңа җыелган чәчәк бәйләмен бер - ике сәгатькә су тулы чиләккә салып торалар. Базардан сатып алган бәйләмне дә, сүтмичә, түнгелеккә салкынча урында калдыралар. Чәчәкләрне вазага куйганчы, суга тиеп торган яфракларны һәм чәнечкеләрне өзеп алырга кирәк. Вазага кайнатып суытылган (20 градус) су салу әйбәтрәк.

Чәчәкләрне өлгергән җиләк - җимеш янында тотарга ярамый. Чәчәкләрнең сулганнарын да ала барырга кирәк. Лалә, канәфер, роза, энҗе чәчәк (ландыш), мәк чәчәге, резеда, күке яше чәчәген (орхидия) бүтәннәр белән аралаштырып куярга ярамый.

Чәчәкләр бик тиз җәрәхәтләнүчән. Шуңа күрә аларны кояшта, эсседә яки салкында, җил үтәли йөри торган урында тотмагыз.

**«ВЫБОР».**

## Хәрефләр сөйли

***Кешенең холык - фигылен беләсең килсә, аның инициалларына игътибар ит. Исем - фамилиядәге баш хәрефләр менә ни сөйли.***

А - көч һәм хакимият.
Б - олы хисләргә сәләтле.
В - аумакайлык, системалылык булмау, үз фикереңдә тора алмау.
Г - серлелек.
Д - аралашучанлык, кешеләрне үзеңә җәлеп итү.
Е - чыдамлылык, тулы әзерлекле булу.
Ж - ышанычсызлык.
З - шикләнүчәнлек.
И - тәэсирләнүчәнлек, киеренкелек.
К - зур ихтыяҗлылык. Аларны борчылып хәл итү.
Л -ваклык, тапкырлык.
М - хезмәт сөючәнлек, үтә вакчыллык.
Н - дәртлелек, иҗади тәкәбберлек.
О - серле дулкынлану, хискә бирелүчәнлек.
П - тыйнаклык, ялгызлык, кешеләрне якын җибәрмәү.
Р - даими киеренкелек, хискә бирелүчәнлек.
С - төшенкелек, боеклык.
Т - туктаусыз эзләнүләр, идеягә омтылу.
У - курку - борчылу.
Ф - ягымлылык, яраклаша белү.
Х - хисләрнең тотрыксызлыгы.
Ц - эчке кичерешләрне тышка чыгаруга омтылу.
Ч - тугрылык.
Ш - көнчелек.
Щ - үч алучанлык, интеллектуаль сәләткә ия булу.
Э - психологик тынычлыкка омтылу.
Ю - тәкәбберлек, таркаулык, эзлеклелек булмау.
Я - зыялылык, иҗади сәләт.

## Белдерүләр

### САТАБЫЗ

**Ашыгыч рәвештә шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир (икенче кат).** Адрес: Козлов ур.,11 - 12, 18.00 сәг.тән соң.

***

**1986 елгы «Москвич - 412 ИЗ».** Циолковский ур., 9 - 41, 17.00 сәг.тән соң.

***

**1996 елгы ВАЗ 21047, 5 баскычлы тизлек күчерү тартмасы, сигнализациясе бар.** Тел.: 2 - 19 - 56.

***

**1997 елгы ВАЗ - 21061, «Алмалык»та дача участогы.** Адрес: К.Маркс проспекты, 2 - 16.

***

**Тотылган кәнәфи - карават, карават, кер юу машинасы, газ плитәсе, кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 19 -22.

***

**1997 елгы, 14мең км. йөргән ВАЗ - 21063, 30 млн.** Адрес: К.Маркс проспекты, 2 - 29.

***

**8 x 11 метрлы өй бурасы.** Зирекледә Рамил Әхмәтовка мөрәҗәгать итәргә.

***

**НГДУ ЖКХсы каршында гараж.** Адрес: Дружба ур., 60 - 13(кич).

***

**Богдашкинода әйбәт хәлдәге йорт.** Тел.: 5 - 27 - 42 ( кичке 6 дан соң).

***

**1987 елгы ВАЗ - 2108 һәм ВАЗ - 21099.** Тел.: 5 - 29 - 66.

***

**1990 елгы «Ока».** Шикәр заводы коммутаторы аша тел.: 5 - 27.

***

**Ике бүлмәле фатир.** Адрес: Завод ур., 25 - 8.

***

**Кормышта өч бүлмәле фатир ( 2 нче кат), 1987 елгы ГАЗ -3110, «Сюита» пианиносы, Некрасовкада дача участогы ( 8 сутый, кирпечтән йорты бар).** Адрес: Дружба ур., 74 - 51, тел.: 5 - 27 - 97.

***

**Тимер юл балалар бакчасы янында бөтен уңайлыклары белән ике бүлмәле фатир.** Тел.: 2 - 16 - 28.

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Чистайда йорт сатыла яки Норлаттагыга алмаштырыла. Вариантлар да булырга мөмкин.** Норлатта тел.: 2 - 18 - 49.

***

**Үзе ясаган мини - трактор сатыла яки автомабильгә алмаштырыла.** Адрес: Красноармейская ур., 11.

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Островский ур., 41 нче йортны - бер бүлмәле фатирга. Гаражы, базы, мунчасы бар.** Тел.: 2 - 10 - 73. 17.00 сәг.тән соң.

***

**Шикәрчеләр микрорайонындагы хосусыйлаштырылган 1 бүлмәле (32 кв. м.)фатирны - килешү буенча шәһәр үзәгендә яки Кормышта шундыйга ук.** Тел.: 5 -20 -47.

### САТЫП АЛАБЫЗ

**Райпоның хәзерләүләр конторасы халыктан килосын 600 сумнан кишер, 300 сумнан аш чөгендере, 400 сумнан бәрәңге сатып ала.**

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Фатир кирәк.** Тел.: 5 - 29 -65.

***

**Кызыл төстәге сыер югалды.** Күрүчеләр булса 2 - 18 - 26 телефоны буенча хәбәр итүләрен сорыйбыз.

## Ветеранның юбилее бүген

***Сугыш һәм хезмәт ветераннарының район Советы рәисе Ислам Усман улы Гыйләҗевкә 70 яшь тулды. Район Советы рәисе буларак Ислам Усманович бу вазифага зур җаваплылык хисе белән карый. Ул райондагы сугыш һәм хезмәт ветераннарының һәм инвалидларының торак -көнкүреш шартларын яхшырту мәсьәләләрен хәл кылуга ул күп көчен һәм энергиясен бирә. Ул Норлатта ветераннар өчен йорт төзелешенә дә зур өлешен кертте. 1996 - 1997 елларда Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидларыннан 31 кеше фатирлар алды һәм торак шартларын яхшыртты. Ислам Усманович урыннарда ветераннарга барьяклы ярдәм оештыруга да зур игътибар бирә.***

***Ислам Усмановичны 70 еллык юбилее белән котлап, аның алга таба да һаман шулай актив, шат күңелле оптимист булып калуын, ветераннар мәнфәгатьләре хакына эчкерсез хезмәтендә аңа гел уңышлар юлдаш булуын телибез.***

Ветераннарның район Советы президиумы.

### ЭШКӘ ЧАКЫРАБЫЗ

**37 нче СМУның 2 нче участогына пневматик йөрешле 16 тонналы кранга кранчы һәм электр белән квалификацияле эретеп ябыштыручы кирәк.** Тел.: 65 - 3 - 11 ( кичке 7 дән 9га кадәр).

**«Норлатнефть» НГДУсы эшчеләрне тәэмин итү бүлеге һәр айда шәһәр һәм район пенсионерларына 200 мең сумга кадәр барлык төр товарларны 3 процент ташлама белән алынасы пенсия хисабына җибәрә ала. Безнең кибетләр 8 сәгатьтән 19 сәгатькә кадәр, төшке ялсыз һәм ял көннәрсез эшлиләр, ә Советская урамының 183 нче йортында урнашкан кибет иртәнге 7дән кичке 9га кадәр сата. Безнең товарларны пенсия хисабына алырга теләүчеләрне үзебездә көтәбез.**

***«Норлат» кунакханәсендә ресторан эшли. Төрле чаралар, тантаналар, юбилейлар үткәрүгә заявкалар кабул итәбез.***



### *Юбилейга рәхим итегез!*

***Шәһәрнең 2 нче мәктәп - гимназиясенең 60 еллык юбилее уңаеннан быелның 16 октябренә билгеләнгән чаралар 25 октябрьгә күчерелә. Тантаналар иртәнге сәгать 10да район мәдәният йортында башлана.***

**Норлат технологик транспорт идарәсенең В 471 ЕВ дәүләт номерлы ВАЗ - 21099 автомашинасына бирелгән документларны ( ЕВ сер. № 169251 белән 1997 елның 17 сентяберендә бирелгән 16 нчы теркәү таныклыгын, 1997 елның 18 сентябрендә бирелгән № 705199 лицензия карточкасын) югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**


**Азык - төлек базарында урнашкан «Альянс» кибетендә сез төрле маркадагы «Норд», «StiNOL» суыткычлары ала аласыз. «Норд» суыткыч техникасы өлкәсендә соңгы казанышларны туплаган, Италиянең әйдәп баручы фермалары детальләре белән комплектланган. Аның хезмәт итү срогы безнең илдә эшләнгәннәрнекеннән күпкә зур. Ассортиментта бер - ике - өч камералы суыткычлар бар. «Альянс» шулай ук «StiNOL», (Атлант) суыткычлары да сата. Әлеге суыткычларның ышанычлылыгына Норлат һәм район халкының күбесе үз тәҗрибәсендә ышанып өлгерде инде.**

***Игътибар: яңалык***

***«Альянс» кибете «Вятка - Аленка» кер юу автоматы сата. ОРТ программасыннан реклама аша сез әлеге машинаның ышанычлылыгына ышана аласыз. Россиянең иң экономияле һәм ышанычлы «кер юучысы» «Вятка - Аленка» Итон (АКШ - Германия), Зертан (Испания), МЭЗ (Словакия) кебек киң танылган фирмалар белән берлектә чыгарыла, аңа «БОШ - СИМОНС», «Электролюкс», «БРАНТ» кебек югары дәрәҗәдәге фирмалар детальләр җибәрәләр. Яңа машина Россия һәм халыкара сыйфат сертификатына ия комплектлаучы детальләрдән җыела, бу исә аның ышанычлылыгын Европа аналоглары дәрәҗәсенә җиткерергә, берочтан сату бәясен дә киметергә булыша.***

***Шулай итеп, «Альянс» кибете сезгә «Норд», «StiNOL», «Атлант» суыткычлары һәм «Вятка - Аленка» кер юу автоматы тәкъдим итә. Гарантия - 2 ел. Октябрь, Чаллы Башы, Аксубай һәм Кошки районнарына илтеп бирү бушлай. Бу товарларны алу өчен сез промышленность базарында Флюрага мөрәҗәгать итә аласыз.***

Лицензия номеры 7076607. Тел.: 5 - 24 - 97.

***Норлат сәүдә базасында сатуда килограммы 9500 сумнан тавык ботлары, Польшада чыккан кондитер әйберләре: килосы 17500 сумнан киң ассортименттан коровка конфетлары, уртача 16 мең сумнан киң ассортиментта печенье, 8 мең сумнан апельсин, 10 меңнән лимон, туңдырылган балык, капчыгы 30 меңнән цемент бар. Шикәр комына һәм югары сортлы онга бартер алмашуы да мөмкин.***

**Идел Буе региональ наркология үзәге**

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* **Табиб М.Б.Багрянцев.**

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 24 октябрьдә, 7 ноябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә. Заказ N 9278.

